| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 сентября 2020г. с.Шалты № 124

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 13 апрелендәге 50 номерлы карарына (16.05.2018 № 51, 15.10.2018 № № 67, 19.11.2018 № 72 үзгәрешләре белән) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын

формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 13 апрелендәге 50 номерлы карарына (16.05.2018 № 51, 15.10.2018 № № 67, 19.11.2018 № 72 үзгәрешләре белән) 2020 елның 1 октябреннән түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының бер тапкыр күләменә исәпләнә;

авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11498 сум тәшкил итә.».

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин